**Яр Чаллы шәһәре Хакиме**
**карары**

**№М 405**
**19.09.2019**

Шәһәр өмәсе
үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистартуны оештыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе 1 бүлегенең 25 пункты, 17 маддәсенең 2 бүлеге, шәһәр Уставының 24 маддәсенең 3 бүлеге, 35 маддәсе 1 бүлегенең 16 пункты, Шәһәр Советының 2006 елның 23 ноябрендәге 16/11 нче карары белән расланган Гражданнарны шәһәр өчен социаль әһәмияткә ия эшләрне ирекле нигездә башкаруга җәлеп итү тәртибе турындагы нигезнамә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2019 елның 19 октябрендә 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү, яшелләндерү һәм санитар чистарту буенча шәһәр өмәсе (алга таба – өмә) үткәрергә.

2. Өмә үткәрү көнендә гражданнарны шәһәр өчен түбәндәге социаль әһәмияткә ия эшләрне башкаруга җәлеп итәргә: яфракларны җыю, чүпләрне җыю, агачлар һәм куаклар утырту, агачларны һәм куакларны санитар кисү.

3. Эшләрне үткәрү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә: парклар, скверлар, яр буйлары һәм бульварлар, шәһәр магистральләре буйлап яшел зоналар, күп фатирлы йортлар янәшәсендәге территорияләр, Кама, Мәләкәс, Шилнә, Челна елгаларының яр буе зоналары.

4. Башкарма комитетка тәэмин итәргә:

1) өмә оештыруны һәм үткәрүне;

2) әлеге карарны «Челнинские известия» һәм «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев